| | | |
|---|---|---|
| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>ШӘҺӘР СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26 декабрь, 2019 ел № 35/5

2020 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль
милкен хосусыйлаштыру Фараз планын
(программасын) раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законга, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезнамәгә таянып,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 2020 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планын (программасын) кушымтага нигезләнеп расларга.
2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
35/5 Карарына
кушымта
26 декабрь, 2019 ел

**2020 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планы (программасы)**

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. 2020 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру фараз планы (программасы, алга таба – Фараз планы) «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законга, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезнамәгә туры китереп эшләнгән.
2. 2020 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милек структурасын оптимальләштерүгә, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итүгә, шәһәр бюджеты керемнәрен арттыруга юнәлтелгән.
3. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруны Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезнамәгә туры китереп, законда каралган ысуллар белән башкару күздә тотыла.

2 бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

4. 2020 елда муниципаль казнада торган һәм муниципаль предприятиеләрдә, учреждениеләрдә файдаланууда булмаган күчемсез милек хосусыйлаштырылырга тиеш.
5. Хосусыйлаштыруга планлаштырылган муниципаль күчемсез мөлкәт исемлеге түбәнге таблицада күрсәтелгән:

| № | Исеме | Урыны | Мәйданы кв.м | Фаразланган хосусыйлаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 16:52:070103:2798 кадастр номерлы гараж һәм 16:52:070103:102, 16:52:070103:103 кадастр номерлы җир кишәрлекләре | ТР, Яр Чаллы шәһәре , 1 нче автомобиль юлы районында “Наиком” ягулык салу станциясе янында | 374,3<br>553,0<br>563,0 | II квартал |

6. 2020 елда муниципаль унитар предприятиеләрне һәм муниципаль милектә булган акцияләрне хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

7. Күчемсез милекне хосусыйлаштыру һәм хосусыйлаштыру шартлары турында, шул исәптән, милекне тартып алу белән бер үк вакытта мондый милекне сатып алучы затка сату башкарылганда, әлеге милек биләгән һәм аннан файдалану өчен зарури булган җир кишәрлеген хосусыйлаштыру шартлары турында карар Шәһәр Советы Карарлары нигезендә Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

8. 2020 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчемсез милек исемлегенә Фараз планының гамәлдәге вакытында Шәһәр Советы Карарлары нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелергә мөмкин.

## 3 бүлек. Яр Чаллы шәһәре милкен хосусыйлаштыруның мәгълүмати тәэмин ителеше

9. Яр Чаллы шәһәре милкен хосусыйлаштыру турында мәгълүматны оператив рәвештә бирү һәм тагын да киңрәк рекламалау максатында, Башкарма комитет әлеге Фараз планының үтәлеше барышында федераль законда каралган тәртиптә массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтеннән файдаланырга хокуклы.